ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2025 п.г.т.Алексеевское № 423

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 18.10.2024 ел, № 440 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру, спорт чараларының календарь планына кертелгән, физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү – күнекмә чаралары үткәрүгә чыгым нормаларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү күнекмә(күнекмә) чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын җайга салу максатында,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 09.04.2025 ел, № 208 «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән, физкультура-савыктыру, спорт һәм күнекмәләр үткәрү чыгымнары нормаларын раслау турында» 2015 елның 18 мартындагы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 18.10.2024 ел, № 440 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының физкультура-савыктыру, спорт чараларының календарь планына кертелгән, физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү – күнекмә чаралары үткәрүгә чыгым нормаларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларын уздырганда спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне, белгечләрне һәм хезмәт күрсәтүче персоналны туклану яисә тәүлеклеклек белән тәэмин итү чыгымнары нормалары» 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә (Кушымта) бәян итәргә;

- «Спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларында катнашучы башка

кешеләрне яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары» 2 нче кушымтада искәрмәгә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларында башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итүгә нормативтан тыш чыгымнарны каплау оешмаларның эшмәкәрлек һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән алган акчалары исәбеннән, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_30.09.2025 ел, № _423_
карарына

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларын уздырганда спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне, белгечләрне һәм хезмәт күрсәтүче персоналны туклану яисә тәүлеклеклек белән тәэмин итү чыгымнары нормалары**

| № т/б | Спорт чаралары исеме | Көнгә бер кешегә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралары | до 365 |
| 2. | Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга күнекмә чаралары(спартакиадалар, универсиадалар) | до 425 |
| 3. | Бөтенроссия ярышлары һәм аларга тренировка күнекмә чаралары | до 730 |
| 4. | Олимпия уеннарына карамаган һәм паралимпиягә карамаган спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга күнекмә чаралары | до 785 |
| 5. | Олимпия һәм паралимпия спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга күнекмә чаралары | до 850 |
| 6. | Алексеевск муниципаль районы территориясендә | до 200 |
| 7. | Алексеевск муниципаль районыннан читтә | до 425 |

Искәрмә:

1. Авырлыгы 90 килограммнан артык һәм / яки буе 190 см дан югары булган спортчыларга аерым очракларда әлеге кушымтада билгеләнгән нормалар каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 50 процентка кадәр күтәрелергә мөмкин.

2. Акчасыз исәп-хисап буенча спорт чараларын уздыру урыннарында туклану яисә тәүлеклек белән тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, спорт чараларында катнашучыларга әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акчалата акча бирү рөхсәт ителә.

3. Спортчыларны, тренер-укытучыларны, машина йөртүчеләрне һәм физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәтү-күнекмә чараларында башка

катнашучыларны яшәү белән тәэмин итүгә нормативтан тыш чыгымнарны каплау оешмаларның эшмәкәрлек һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән алган акчалары исәбеннән, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Чараларны үткәрүче оешмалар бюджеттан тыш, иганәчелек акчалары, шулай ук заявка кертемнәре исәбеннән барлык категория судьяларга, спортчыларга, тренерларга, машина йөртүчеләргә һәм белгечләргә туклану өчен компенсация түләүләре яисә тәүлеклек түләүләр башкарырга хокуклы.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**